ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ
ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

һ.Такташ урамы, 94 нче йорт, Казан шәһәре, 420107

тел. (843) 278-92-00, факс (843) 278-91-92, e-mail: gosalcogol@tatar.ru, http://gosalcogol.tatar.ru,
ОКПО 42151664, ОГРН 1021602865239, ИНН/КПП 1654025044/165901001

# БОЕРЫК

13.03.2023 Казан ш. № 10-07/30

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 11.03.2021 ел, № 10-07/41 боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында (кадрлар резервына)» Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатыннан боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 11.03.2021 ел, № 10-07/41 боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында (кадрлар резервына)» Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләре белән алыштырырга;

4.12.4 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләре белән алыштырырга.

4.12.4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Тестлаштыру Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе

каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган «Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарны тестлаштыруны оештыру мәсьәләләре» тестлаштыру методикасына туры китереп башкарыла.».

2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи затка әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **Җ.Й. Әхмәтханов**